**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Советы**

**КАРАР № 2**

Масловка авылы 28 март, 2022 ел

Җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты нигезендә Масловка авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1)Җир салымы һәм физик затлар мөлкәтенә салым, әлеге салымнар пенялар һәм штрафлар буенча бурыч буенча недоимканы түләтүгә ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләр билгеләргә:

варислардан мирас хокуктан баш тарткан, варислар булмаган яисә мирас ачылган көннән бер ел дәвамында мирас кабул итмәгән очракта, вафат булган яисә вафатбулган физик затларнын недоимкасы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычы булу

2) Җир салымы һәм физик затлар мөлкәтенә салым буенча недоимканы түләттерүгә, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслаучы документлар булып тора:

физик затның яшәү урыны буенча салым органының недоимка һәм пенялар һәм штрафлар буенча бурычлар турында белешмәсе;

физик затларның гражданлык хәле актларын теркәүне гамәлгә ашыручы орган тарафыннан физик затның үлем фактын теркәү турында белешмәләр;

мирас хокукы турында таныклык бирү турында белешмәләрнең булмавы турында салым органы белешмәсе.

3) Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4) Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлегенең Масловка авылы, Үзәк урамы, 13 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Масловка авыл җирлеге Башлыгы А.И.Егоров